| МИНИСТЕРСТВО ЗДРАВООХРАНЕНИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**14.12.2021** г. Казань № **2777**

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «Опека, попечительлек (шул исәптән алдан опека һәм попечительлек) билгеләү, опекунны (попечительне) үз вазыйфаларын үтәүдән азат итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 19.12.2019 № 2544 боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатыннан боерам:
Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «Опека, попечительлек (шул исәптән алдан опека һәм попечительлек) билгеләү, опекунны (попечительне) үз вазыйфаларын үтәүдән азат итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» (Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 13.11.2020 ел, № 1947, 17.05.2021 ел, № 890, 10.08.2021 ел, № 1628, 08.11.2021 № 2462 боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән) 19.12.2019 № 2544 боерыгына кертелә торган, кушымта итеп бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр М.Н.Садыйков

14.12.2021 № 2777
Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау министрлыгы
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «Опека, попечительлек (шул исәптән алдан опека һәм попечительлек) билгеләү, опекунны (попечительне) үз вазыйфаларын үтәүдән азат итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 19.12.2019 № 2544 боерыгына кертелә торган үзгәрешләр

Боерыкның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Кушымта итеп бирелә торган Опека, попечительлек (шул исәптән алдан опека һәм попечительлек) билгеләү, опекунны (попечительне) үз вазыйфаларын үтәүдән азат итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентны расларга.»;

Боерык белән расланган, Опека, попечительлек (шул исәптән алдан опека, попечительлек) билгеләү һәм опекун (попечитель) билгеләү, опекунны (попечительне) үз бурычларын үтәүдән азат итү буенча (суд тәртибендә эшкә сәләтсез яки эшкә чикләнгән сәләтсез дип танылган балигъ булмаган затларга карата) дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентының исемен, түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Опека, попечительлек (шул исәптән алдан опека һәм попечительлек) билгеләү, опекунны (попечительне) үз вазыйфаларын үтәүдән азат итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты».